# Чишмә башы

**Хәсәншәех балалар бакчасы**

**6 нчы сан, апрель**



**Апрель-кошлар ае. Безнең канатлы дусларыбызның күбесе җылы яктан шушы айда очып кайталар.** “Кошлар көне”- ел саен үткәрелә торган экологик бәйрәм. Ул 1 нче апрельгә туры килә, чөнки нәкъ шушы вакытта кошлар туган якларына кайта. Беренче булып кара каргалар очып килә, алардан соң сыерчыклар күренә башлый. Соңрак тургайлар, күкеләр, сандугачлар, карлыгачлар очып кайталар. Кошлар килгәч, табигать тагын да матурлана.



**Россиядә кошлар көне барлыкка килү тарихы бик кызыклы. 19 гасырда безнең илгә килеп ирешкән канатлыларга ярдәм оештыру идеясе игелекле кулларга эләгә. Шушы чорда кошларны саклау чаралары оештырыла, 20 гасыр башына бу эш белән дистәләгән оешма шөгыльләнә башлый. Шәһәрләрдә балалар өчен оешмалар ачыла. Алар мәктәп базасында 9-11 яшьлек балалар өчен оештырылган. Мондый оешмага йөрүчеләрнең баш киемнәрендә оча торган карлыгач эмблемасы ясалган булган**



**Революциядән соң 1917 елда кошлар саклауны яшь натуралистлар дәвам итә. СССР да 1926 елдан әлеге датаны рәсми бәйрәм буларак билгеләп үтәләр. Ел саен уза торган Кошлар көнен сугыш тоткарлый, әмма 1948 елда хәрәкәт яңартыла. 20 гасырның 60-70 елларында әлеге көнне билгеләү юкка чыга. 1993 елда оешкан Россия кошлар саклау берләшмәсе 1999 елда бәйрәмне яңадан торгыза.**




Соңгы елларда табигатьне саклау,балаларга экологик тәрбия бирү-иң зур проблемаларның берсе булып тора.Чөнки сулаган һавабыз,эчкән суыбыз пычранып бетә,табигать,бөтен тереклек зур куркыныч астында калды .

Экологик проблемалар педагогларны да битараф калдырмича,балаларга экология тәрбиясе бирү бурычын куя .Моны кече яшьтән башларга кирәк .

Безнең максат –мәктәпкәчә яшьтәге балаларны туган як табигатенең үсемлек һәм хайваннар дөнясы белән таныштыру,аларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.Табигатьне күзәтү,аны өйрәнү,сакларга омтылу-балаларның рухи дөнясын баета,уйларга өйрәтә.

Бакчабызда һәр төркемдә экологик почмак булдырдык.Анда яшь үзенчәлекләренә туры килә торган гөлләр куйдык.Балалар һәркөнне гөлләрнең ничек үскәнең,чәчәк атуын күзәтәләр ,төпләрен йомшарталар,тузанын сөртәләр,сулар сибәләр .Шау чәчәктә утырган гөлләрнең матурлыгына сокланалар.Кышын тәрәзә төпләрендә суганың үстерү,аның үсешен күзәтү балалар өчен бик кызык .Ел әйләнәсе кошларны күзәтәбез.”Кошларга җимлек “акциясе оештырабыз.Кошларны даими тукландырып торабыз.Ә матур язлар җиткәч “Кошлар көне “үткәрәбез Сыерчык ояларына конкурс була .Сыерчык ояларын агач башларына урнаштырып ,сыерчыкларның кайтуын көтәбез.”Табигатькә – агач бүләк ит ! акцияләрендә катнашабыз .Әти –әниләр балалар белән берлектә агач куаклар утырталар .Аларны тәрбияләп яшәрүен көтәбез .Кече яшьтән үк балаларның табигатьне сакларга ,аны яратып үсүләрен телибез.

# ЭКОЯЗ - 2025



1 апрельдән Татарстанда традицион «Экояз»республика конкурсы старт алды. Узган елдагы кебек үк, конкурс экологик квест формасында уздырыла, аның биремнәре атна саен үзгәрәчәк. Быел " ЭКОяз " Ватанны саклаучылар елына һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган. Бу чараларда балалар да ,әти-әниләр дә бик теләп катнашалар..











# *Туган телем сагында*



Г. Тукай - балалар поэзиясенең чишмә башы, нәниләрнең сөекле остазы. Бүген дә актуальлеген югалтмаган әсәрләре балаларны тәрбияләүдә үрнәк булып тора. Әйтерсең, Тукай берничә гасыр алга карап, фикер йөрткән, шул вакытта ук һәрьяктан камил шәхес тәрбияләү мәсьәләсен күзаллый белгән.



Бездә балалар бакчасында Г. Тукай әсәрләре аша һәрчак акыллы, тапкыр, нык ихтиярлы, батыр йөрәкле булырга өйрәтү өстендә эшлибез.

Яшь үзенчәлегенә карап,шигырьләр ятлау, әкиятләр белән танышып, сәхнәләштерү, шулар аша дөрес, матур итеп сөйләшү максат итеп куела.

Г. Тукайның туган көненә багышлап ел саен балалар бакчасында зур бәйрәм үткәрәбез. Быел да балалар Г. Тукайның шигырьләрен яттан сөйләделәр. Кәҗә белән Сарык әкиятен сәхнәләштерделәр. Туган тел җырын бергәләп җырлап, бәйрәмне тәмамлады лар. Кәҗә белән Сарык әкияте аша да балалар тапкырлык сыйфатларын үзләрендә булдыра алдылар.



Димәк, Тукай әсәрләре балаларга телебезнең матурлыгын аңларга, үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга, туган җиребезгә, туган телебезгә, әти-әниләргә карата мәхәббәт, хөрмәт тәрбияләвенә ярдәм итүен аңлап эшлибез.